**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 сентябрь № 726

г. Казань

Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең төп (тармак) исемлеген төзү һәм алып бару, федераль дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзү, алып бару һәм раслау турында һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) күрсәтә һәм башкара торган дәүләт (муниципаль) хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзүгә, алып баруга һәм раслауга гомуми таләпләр хакында» 2014 ел, 26 февраль, 151 нче карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу акарга теркәлгән Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт нигезендә төзелгән дәүләт бюджет яки автоном учреждениеләрнең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына, шулай ук карамагында казна учреждениеләре булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә (алга таба – гамәлгә куючы вәкаләтләрен башкаручы органнар), Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләт хезмәтләре

һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзегәндә һәм раслаганда, әлеге карар белән расланган Исемлеккә таянып эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче;

«Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карарына үзгәреш кертү хакында һәм Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан башкарыла һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт эшләре исемлеген раслау турында» 2011 ел, 10 декабрь, 1009 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 ел, 3 ноябрь, 938 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 14 ноябрь, 873 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карарына үзгәреш кертү хакында һәм Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан башкарыла һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт эшләре исемлеген раслау турында» 2011 ел, 10 декабрь, 1009 нчы карары белән расланган Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан башкарыла һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт эшләре исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2014 ел, 14 апрель, 241 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 4 июнь, 378 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 21 август, 602 нче.

4. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\726.docx